Хөрмәтле авылдашлар!
Килгән кунаклар!

Һәр елны январь, февраль айларында, авыл җирлекләрендә, авыл башлыклары, үзләренең халкы, сайлаучылары алдында башкарылган эшләренә отчет ясый, алга таба бурычлар, йөкләмәләр билгели. Шулай ук бу җыелышта авыл халкы, район башлыгы, район башкарма комитеты җитәкчесе һәм аның ярдәмчеләре, район пенсия фонды, социаль яклау хезмәткәрләре, БТИ оешмасы, җир һәм милек комитеты җитәкчеләре, районның башка оешма җитәкчеләре белән очраша. Алар республика, район яңалыклары белән таныштыра, башкарылган эшләр, алда торган бурычлар, халыкны борчыган төрле сорауларга җавап бирәләр.

Исәнбай авыл җирлегенең отчет чорында 10 авыл җирлеге Советы утырышы җыелып, анда 18 көн тәртибе каралды. Бу утырышларда барлык Исәнбай авыл җирлеге округлары депутатлары да актив катнаштылар, һәм авыл тормышына кагылышлы тәкъдимнәр ясадылар. Утырышларда Исәнбай авыл җирлегенең уставына үзгәрешләр кертү, бюджет кабул итү, аңа үзгәрешләр кертү, җирле салымнар җыю, коммуналь тарифлар, учреждение- предприятие эшләрен оештыру, бәйрәмнәр уздыру һәм башка мәсьәләләр каралды. Авыл җирлеге Советы утырышларының карарларын халыкка җиткерү өчен информацион стендка элеп куелды.

Исәнбай авыл җирлеге территориясендә 422 хуҗалык бар. Торак фонды 18 мең кв. метр тәшкил итә. Авылда барлыгы 942 кеше яши. Соңгы елларда авылдагы хуҗалыклар саны да даими яшәүчеләр саны да кимегән. 2013 елда 5 бала туу акты, башкарма комитеты тарафыннан 26 үлем акты теркәлде, 8 пар яшьләргә язылышу турында таныклык тапшырылды.

Авылда яшәүче 942 кешенең: 429ы- ир-атлар- 45,5%, 513е- хатын-кызлар- 54,5% тәшкил итә. Яшьләр буенча 1-6 яшькә кадәр -56 бала, 7-17 яшькә кадәр - 109 бала, 18-30 кадәр - 172 кеше, 30-40 яшькә кадәр - 98 кеше, 41-50 яшькә кадәр - 144 кеше, 51-60 яшькә кадәр - 148 кеше, 60 яшьтән өлкәнрәкләр- 224 кеше яши. авылда яшәүче халыкның уртача яше 42 яшькә туры килә. Пенсионерлар – 235, студентлар – 31, эш яшендә төрле оешма-учреждениеләрдә эшләүчеләр -529 кеше.

Авыл җирлеге Советы һәм башкарма комитетының төп бурычы булып, сугыш һәм хезмәт ветераннарына, гомумән авылыбыз халкы турында кайгырту, аларның үтенечләрен, теләкләрен, киңәшләрен тыңлап, аларны хәл итү, авыл җирлегенең төп бурычларның берсе. Авыл җирлегендә бүгенге көндә бер сугыш ветераны Тютеев Сәгыйт абый, бер Совет Армиясе инвалиды, 4 Әфган һәм 5 Чечен Республикасында хезмәт итеп кайтучылар, репрессиялеләр- 3, хезмәт ветераннары- 112, инвалидлар- 73, тыл ветераннары -51, ялгыз яшәүчеләр 16 кеше.

Авыл җирлеге Советы, башкарма комитеты, мәдәният йорты, авылда урнашкан оешмалар, учреждениеләр, Бөек Җиңү бәйрәме- 9 май, өлкәннәр көнен зур хәзерлек белән билгеләп үттеләр. Өлкәннәр һәм инвалидлар декадасында авыл җирлеге башкарма комитеты һәм оешма предприятиесе җитәкчелеге, авылыбызның һәрбер өлкән кешесен зурлап кечкенә генә булсада бүләкләр тапшырдылар, кайбер оешмалар түгәрәк өстәл янында кайнар чәйләр белән сыйладылар, ә мәдәният йорты хезмәткәрләре авылыбыз өлкәннәре “Мирас” ансамбле һәм үзешчәннәре көче белән зур концерт программасы куйдылар. 2013 елда авыл җирлеге башкарма комитеты, агрофирма һәм шәхси эшмәкәрләр булышлыгы белән корбан бәйрәме уңаеннан, корбан чалынып, авылыбызның өлкәннәре белән корбан ашы үткәрелде. Бу корбан бәйрәмен уздыруда булышкан хезмәткәрләргә зур рәхмәт белдерәсе килә.

Район социаль ярдәм идарәсе 2013 елда Исәнбай авыл җирлегендәге гражданнарга 392 кешегә, социаль ярдәм күрсәткән, шул исәптән федераль льготникларга, инвалидларга, әз тәэмин ителгән гаиләләргә, күп балалы гаиләләргә, балалар бакчасына йөртү өчен компенсация, балалар пособиесе, 1,5 яшенә кадәр пособие түләнгән. Материаль ярдәм 8 кешегә 36 000 сум күләмендә бирелде.

Авылда караучысыз калган 9 өлкән кешеләргә 2 социаль һәм бер медицина хезмәткәре хезмәт күрсәтә. 80 яшьтән узган 32 кешене тәрбияләү буенча кешеләр беркетелгән. Красный бор тернәкләндерү үзәгендә 21 пенсионерлар ял итеп, сәламәтлекләрен ныгытып кайттылар.

Авыл җирлеге территориясендә яшәүче халык үзләренең үтенечләре белән совет һәм башкарма комитетына мөрәҗәгать

итәләр. Гражданнардан кергән үтенечләр күп төрле. Мөрәҗәгатьләрнең күпчелеге өлкән яшьтәгеләр тарафыннан хезмәт стажын эзләү, тиешле льготалардан файдалану турында. Төрле оешмаларга гаилә хәле, яшәү урыны, агач материаллары, полиция органнарына, хуҗалыкларында терлек булуга карата, коммуналь мәсьәләләр, җир пае, милек рәсмиләштерү һәм башка күп төрле белешмәләр бирелә. Исәнбай авыл җирлегендә гражданнарны кабул итү авыл җирлеге башлыгы, башкарма комитеты урынбасары тарафыннан башкарыла. Кабул итү урыны Исәнбай авыл җирлеге бинасында, кабул итү өчен көннәр һәм сәгатьләр билгеләнгән.

Авыл җирлегенең материаль ярдәм күрсәтү чыганагы булмаса да, мөрәҗәгать итүчеләргә, хөрмәткә лаеклы иптәшләргә булышлык күрсәтүдән читтә калмый. Бигрәктә район оешмалары белән хәл ителәсе мәсьәләләрне үз өстебезгә алырга, вакытында җавап бирергә тырышабыз. Шунысын әйтәсе килә, соңгы елларда район пенсия фонды, социаль яклау хезмәткәрләре, БТИ оешмасы, җир һәм милек комитеты хезмәткәрләре, авылга килеп халык белән очрашалар, ярдәм итәләр. 2013 елда Исәнбай авыл җирлеге башкарма комитеты, җир пайлары булган гражданнарның, җир пайларын дәүләт регистрация палатасы аша үткәреп, һәрбер җир пае булган гражданнарга таныклыкларын алып бирүдә зур булышлык күрсәттеләр. Форсаттан файдаланып җир пайларының таныклыкларын алып бирүдә булышлык күрсәткән авыл җирлеге башкарма комитеты хезмәткәрләренә зур рәхмәт әйтәсе килә.

Хөрмәтле авылдашлар!

Бүгенге көндә авылда яшәүче шәхси хуҗалыклардагы терлекләр саны түбәндәгечә:

	01.01.2013	01.01.2014	
Мөгезле эре терлек	421	335	-86
сыерлар	143	131	-12
таналар	28	23	-5
Сарык һәм кәҗәләр	230	175	-67
Атлар	15	15	-
Кош-кортлар	1083	1099	+16

Бал кортлары	293	324	+31

Авыл җирлегендә шәхси хуҗалыклардагы сөт җыю, сату буенча Мухаммадиев Рәис авыл хуҗалыгы “Дуслык” кооперативы шөгелләнә. Ел әйләнәсе 2 516 ц сөт халыктан җыелган һәм сатылган. Мухаммадиевлар һәр ай саен вакытында халыктан сөт җыйган өчен акчаларын түләп баралар. Барлыгы 2 843080 сум акча таратылган. Уртача 1 литр сөтнең бәясе 11 сум 30 тиен, димәк һәр литр сатылган сөт гаиләгә өстәмә табыш. 2013 елда иң күп сөт тапшырган хуҗалыклар:

	ФИО	литр	Сумма
	Шәмсетдинов Котдус	22 593	254 453
	Тукманов Илшат	10 075	116 354
	Шарипов Миннерәхмән	8 769	98 741
	Мухьянов Наил	8 065	91 876

Шуны әйтәсе килә: халыктан җыелган сөтнең бәясе түбән булуы борчый. Исәнбай авыл җирлегендә яшәүчеләр, шәхси хуҗалыкларында малны күп асрый. Ләкин 2013 елда мөгезле эре терлек итенә бәяләрнең түбән булуы, 160-185 сум. Симертелгән итне теләгән хакка кая урнаштырып булмау, арзанга сату сәбәпле, күп хуҗалыклар баш санын бермә-бер киметте. Авыл халкы җитештергән итләрен, үз хуҗалыкларыннан артканын сата. 2013 елда 173 баш, 692 ц тере авырлыктагы маллар сатылган һәм 6 млн. 500 мең сумлык артыграк продукция җитештерелгән. Шулай ук бал кортлары тотучы шәхси хуҗалыклардан 40 ц якын бал сатылган.

Соңгы елларда авыл халкының тормыш шартларын яхшырту, үзләренең эшләрен башлап җибәрү максатыннан дәүләт тарафыннан төрле льготалы (ЛПХ) кредитлары бирелә. 2013 елда авыл җирлегендә барлыгы 12 хуҗалык 3 110 000 сумлык кредит алган. Соңгы 2006-2013 елларда 68 хуҗалык 7 млн. 854 мең сумлык кредитын кушсаң, зур сумма килеп чыга. 2013 елда хөкүмәтебез сыер тоткан хуҗалыкларга 2 000 сум күләмендә датация акчасын бирде. Мөгезле-эре терлекләргә фураж, печән хәзерләргә, сатып алырга, сыер тоткан хуҗалыклар өчен бу өстәмә файда булды.

Авыл җирлегендә шәхси хуҗалыкларда техникалар, авыл хуҗалыгы машиналары булуга карамастан, крестьян- фермер хуҗалыгы, семья фермалары ачып пай җирләрен алып файдаланучылар юк диярлек.

Хөрмәтле авылдашлар!

2013 нче елның бюджет үтәлеше буенча түбәндәгеләрне әйтергә мөмкин. Доход өлеше 2 510781 мең сум булса, расход өлеше 2 679223 сум тәшкил итә.

Налоглар җыю буенча түбәндәге саннарга тукталып китәсе килә. Физик затлар кереме 180 000 сум булырга тиеш булса, ул 218 000 сум, җир налогы 188 664 сум, милек налогы 164 572 сум, транспорт налогы 232 323 сум. Ел дәвамында 40 500 сум үзарасалым, 164 900 сум су кулланган өчен, 9 000 сум мәдәният йортының түләүле хезмәте, Исәнбай аерым янгын сүндерү депосының электр утына һәм коммуналь түләүләр 17 415,09 сум акча керде. Шулай ук загс, госпошлина һәм арендадан 91 529 сум акча җыелды.

Бүгенге җыелыштан файдаланып, әйтәсе килә, налоглар җыйганда һәрбер хуҗалык үзенә тиешле налогны үз вакытында түләсен иде.

2013 елда үзарасалым кеше башына 100 сумнан җыелды. Быелда 100 сум дисәк, нәрсә диярсез? Тавышка куям.

Бюджетка үзарасалым һәм су өчен 205 400 сум җыелган акчадан, ДРЛ электр лампалары, дроссельләр, су краннары, полителен, резина шланглар өчен 40 220 сум, су магистральләрен көйләү, ремонтлау, чүплекләрне тәртиптә тоту өчен 70 000 сум, урамнарны кардан чистарту 15 000 сум, шулай ук налоглар, 17 000 сум һәм 9 май, өлкәннәр көнендә бүләкләү өчен 25 000 сум акча тотылды.

Хөрмәтле авылдашлар!

2012-2013 елларда авылыбызда зур үзгәрешләр булды. Исәнбай гомуми урта белем бирү мәктәбенә һәм халыкка медицина ярдәме күрсәтүче үзәк амбулатория бинасына капиталь ремонт, авылыбызның Совет урамына щебенкалы юл салынды. Һәр елны авыл җирлеге Советы һәм башкарма комитетының отчет җыелышында авыл уртасында урнашкан мәдәният йортының түбәсен алыштыру мәсьәләсе куела иде. Бу мәсьәлә ел азагында хәл ителеп, мәдәният йортының түбәсе яшел профнастил калай белән ябылды. Бу эшне оештырып, башкарып чыгуда, авылдашыбыз “ Татарстан күперләренең “ генераль директоры Мухьянов Ренат Сәгыйт улы материаль һәм 500 мең сумлык матди ярдәм күрсәтте.

Бүгенге җыелыштан файдаланып, шуны әйтәсе килә, Исәнбай авыл җирлеге Советы һәм башкарма комитеты, гомумән барлык авылдашлар исеменнән, мәдәният йортының түбәсен ябуда, спонсорлык булышлык күрсәткән авылдашыбыз “ Татарстан күперләр “ енең генераль директоры, ТР атказанган төзүчесе Мухьянов Ренат Сәгыйт улына чиксез зур рәхмәтебезне җиткерәсе килә һәм аңа саулык-сәламәтлек, эшләрендә зурдан-зур уңышлар, авыл халкын шулай сөендергәне, изге эшләре өчен, алдагы еллар шатлык, бәхетләр алып килсен.

Шулай ук авылыбыз юлларын төзекләндерү эшләре буенча Октябрь урамына кирпеч заводыннан алып янгын сүндерү депосына кадәр 450 метр га якын урам юлларын, янган кирпеч калдыклары җәелеп яңартылды һәм яшьләр урамына 500 метр га якын арага шулай ук янган кирпеч калдыклары түшәлде. Бу эшләрне башкаруда авылыбызның кирпеч җитештерү предприятиесе җитәкчесе изге күңелле, һәрвакыт булышлык күрсәтүче авылдашыбыз Нурмехаметов Шәйхенур мулланур улына зур рәхмәт әйтәсе килә. Быелда 2014 елда бу эшләрне яшьләр һәм кирпеч урамнарын көйләүне дәвам итәргә кирпеч заводы җитәкчеләре булышлык күрсәтүен белдерәләр. Узган ел Исәнбай пожар депосының бинасына да газ кертү эшләре башкарылды. Авылыбыз һәм чит җирләрдә яшәгән авылдашлар булышлыгы белән җыелган акча исәбенә, мәчет коймасын яшел профнастил калай белән тотылды. Шулай ук авылыбызның мәчеткә йөрүче бабайлар, абзыйларның хыяллары тормышка ашты, мәчетебезгә газ кертү эшләре төгәлләнде. Мәчеткә газ кертү өчен: кирәкле документлар, материаллар, кателлар, гомумән булышлык күрсәткән авылыбызның һәрбер хуҗалыгына, читтә яшәүче авылдашларга зур рәхмәтебезне җиткерәсе килә һәм бигрәктә бу эштә зур өлеш керткән авылдашларны әйтеп китмичә булмый торгандыр:

1. Гәрәева Гөлсинә- 1 000 сум
2. Җәмилев Хәмит- 1 000 сум
3. Шәрипов Наил- 1 000 сум
4. Шәрипов Дилүс- 1 000 сум
5. Халимова Фәһимә- 1 300 сум
6. Симаков Раил- 2 150 сум
7. Маннанов Рәшит- 2 500 сум

8. Шәрипов Сәетҗан- 2 800 сум
9. Сираева Рәшидә- 4 200 сум
10. Хөснетдинова Эльвира – 5 000 сум
11. Гильфанов Баян- 5 000 сум
12. Гайнуллина Рәшидә- 7 000 сум
13. Мухьянов Ренат- 10 000 сум
14. Ижболдина Эльза- 14 000 сум
15. Музафаров Хәтәм – 18 483 сум
16. Маннанов Рәкыйп- 44 000 сум

Ел дәвамында мәчетнең электр утына, зыярат коймаларын яңарту, мәчет коймасын профнастил калай белән тоту һәм газ документларын хәзерләп, мәчеткә зәңгәр ягулык керту өчен барлыгы 208 500 сум акча җыелды. Шулардан:

1. Мәчетнең утына- 17 217 сум,
2. Мәчетнең тех паспортын эшләтү өчен- 21 575 сум,
3. Газ проектын эшләтергә - 18 000 сум,
4. Газ котеллары, торбалар:
5. гомумән газ керту өчен- 141 874 сум,
6. Мәчетнең коймасын, эчке эшләрен эшләү өчен - 86 604 сум,
7. Корбан ашы үткәрүгә- 4 273 сум
8. Корбан сарыгы алу өчен -6 000 сум акча тотылды һәм бүгенге көндә мәчет кассасында 8 100 сум акчасы бар.

Хөрмәтле авылдашлар!

Урамнарны яктырту, халыкны су белән тәэмин итү, урам юлларын ремонтлау, төзекләндерү кебек, кыш көне юлларны кардан чистарту, халык ихтыяҗларын кәнагатьләндерү юнәлешендә эшләр башкарылды. Берничә сүз белән әйтеп китәсе килә, ДРЛ лампалары белән урамнарны яктырту, тулысынча электр кушу, аеру приборлары, электр счетчиклары ярдәмендә башкарыла. 60-70 нче елларда уздырылган 16 км артык су системасы, магистральләре тузган. Ел саен 10-12 җирдә магистральләр тишелә, колонкалар ватыла. 2013 елда ел дәверендә бер су насосы алыштырылды, 10 урында Совет, Ленин, Мәктәп, машина- трактор паркында, Октябрь урамнарында су магистральләре ремонтланды һәм без ремонт эшләрен 2014 елда да башкарачакбыз.

Авылыбызның урам юлларын төзекләндерү эшләре буенча докладта алда әйтеп кителде һәм бу эшләрне авыл

җирлеге башкарма комитеты, кирпич заводы җитәкчелеге белән берлектә алып барачак. Һәр елда халыкны борчыган мәсьәләләрнең берсе, Биме елгасын буу, быелда бу эшне планлаштырабыз, чөнки авыл халкына, терлекләргә өстәмә рәвештә су чыганагы, балаларга һәм өлкәннәргә су коену өчен бик файдалы.

Авыл җирлеге территориясендә ике җитештерү предприятиесе бар. 12 учреждение- предприятиеләр урнашкан. Авыл халкы өчен культура, медицина, белем бирү, балалар бакчасы, сәүдә, почта, саклык банкы, аптека, АТС, янгын сүндерү депосы, ветеринар участогы- барсыда бар. Авыл халкына тормыш итәргә, яшәү өчен бөтен уңайлыклар тудырылган. Җаваплылыгы чикләнгән "Нәүрүз" һәм Агро-Кама оешмасының Исәнбай бүлекчәсендә 114 кеше эшли. Исәнбай бүлекчәсе игенчеләре ашлыктан тулаем җыен 35 193 ц гектарыннан 18 ц артык иген уңышы җыеп алдылар. Кышлату чорына җитәрлек күләмдә сенаж 1500 т, силос 3070 т, печән 187,6 т, салам 1221,3 т бер баш терлек 25 ц артык азыгы хәзерләнде. Бүгенге көндә 690 баш мөгезле-эре терлек, шулардан 335 баш савым сыерлары бар. 2013 елда 9192 ц сөт савылды, бер сыерга 3000 л якын сөт туры килә, 399 ц ит җитештерелде һәм сатылды. Алга таба терлекчеләргә һәм белгечләргә, алдагы елларда малларның баш саннарын киметмәү өчен, җаваплылык сизеп, тырыш хезмәт куеп, сөт җитештерү дә уңышлы эшләүләре кирәк. Кыскасы, әгәрдә ферма коллективы бер баш сыерга ел дәвамында 4000 л артык сөт җитештерсә, фермалар яшәр, ә инде 3000 литрдан кимрәк чөт саусалар, авылдагы сыер фермаларының яшәүләре икеле. Бүгенге көндә Исәнбай бүлекчәсенең игенчеләренең механизаторлар, белгечләрнең язгы-кыр эшләренә тракторларны, машина һәм тагылмалы авыл хуҗалыгы техникаларын ремонтлау, язгы-кыр эшләрен кыска срокларда, үзвакытында башкарып чыгу бурычы тора. 2013 нче ел өчен Агрофирма авыл халкына пай җирләрен арендалаган өчен бер пайчыга бер ц исәбеннән ашлык бирде.

Исәнбай кирпеч заводында даими 32 кеше сезон вакытында -60 тан артык кеше хезмәт куя. 2013 елда 3 млн. артык кирпеч җитештерелде. Аларның җитештергән кирпечләрен Әгерҗе шәһәре һәм районнардан, авыллар, Сарапул, Чаллы, Казан һәм башка шәһәрләргә алып китәләр, җитештерелгән

продукциягә, кирпечкә сорау зур, кирпечнең сыйфаты яхшы булгач, продукция үзвакытында сатыла. Бүгенге көндә дә кирпеч заводы эшчеләре яңа сезон өчен ремонт, реконструкция, урман кисү, агач-материаллары, утын хәзерләү эшләре белән шөгельләнәләр.

Исәнбай урта гомуми белем бирү мәктәбендә 86 укучы белем ала. Аларга 14 укытучы белем бирә, барлык фәннәр буенча белгечләр укыта. 2013 нче елның ярты еллыгын 100% өлгереш 54 % сыйфат белән йомгакладылар. Бүгенге көндә безнең мәктәбебезне тәмамлаган 31 укучы югары һәм махсус белем бирү йортларында укуларын дәвам итәләр. Мәктәбебез укучылары оештырылган район олимпиадаларында, класстан тыш эшләр үзәге оештырган район һәм республика күләмендә призлы урыннарны яулыйлар. Һәрвакыт спорт ярышларында, бигрәк тә татар-башкорт көрәшендә алдынгы, беренче урыннарны яулыйлар.

Исәнбай авыл җирлеге территориясендә ясле-бакча яшендә 36 бала бар. Шуларның 30 бала балалар бакчасына йөри. 2014-2015 елларга фаразлар буенча балалар бакчасына 30-34 бала йөриячәк. Кадрлар белән балалар бакчасы тулаем комплектланган. Ел дәвамында балалар бакчасы коллективы кече яшьтәге балаларны тәрбияләү, балаларның физик үсешләрен камилләштерү, мәктәп һәм ата-аналар белән тыгыз элемтәдә торып, алда торган бурычларны хәл итүдә бергәләп эшлиләр. Балалар бакчасы ачылганга 30 ел артык вакыт үткән, балалар бакчасына капиталь ремонт бер тапкырда ясалмады. Бүгенге көндә балалар бакчасының тәрәзә- ишекләрен пластик тәрәзәләргә алыштырасы, сантехника һәм канализацияләренә ремонт ясау кирәк.

Исәнбай амбулаториясе тугызбуй зонасындагы 11 авыл халкына 3880 кешегә медицина хезмәте күрсәтә. Шуларның 1963 хатын-кызлар, 675- 18 яшькәчә балалар, хезмәт яшендә 2003 кеше, пенсионерлар -1074 кеше. Амбулаториягә 9 ФАП беркетелгән, аларда 12 фельдшер һәм акушер эшли. Амбулатория кадрлар белән тәэмин ителгән. бер гомуми практик табиб, бер врач – стомотолог, бер фельдшер – лаборант, 4 гомуми практик медсестра, 2 шәфкать туташы эшли.

Докладта алда әйтеп кителгәнчә, амбулаториядә капиталь ремонт ясалды. Бүгенге көндә амбулаториянең медицина

хезмәткәрләре яхшы, җылы, бөтен уңайлыклары булган бинада халыкка медицина ярдәме күрсәтәләр. Амбулаториядә стомотология, клиник лаборатория, физ. кабинет, процедурный һәм башка кабинетлар эшләп тора. Бүгенге көндә 5 койка көндезге стационар эшли. Амбулаториядә эшләүче һәр медицина хезмәткәре урын өстендә ятучы авыруга, инвалидларның хәлләрен җиңеләйтү өчен бар тырышлыкларын куялар, вакытында тиешле медицина процедураларны үткәрәләр.

2014 нче ел- республикабызда культура- мәдәният елы дип игълан ителде. Авылыбызның мәдәният йорты 1973 елда ачылган, 40 елдан артык бинага капиталь ремонт үткәрелмәгән. алда докладта әйтелгәнчә мәдәният йортының түбәсенә спонсорлык булышлыгы белән түбә калае алыштырылды. Бүгенге көндә бинаның ишек, тәрәзә ремонтларын, электр үткәргечләрен, эчке һәм тышкы ягына косметик ремонт эшләрен башкарырга кирәк. Мәдәният йортына капиталь ремонт үткәрү өчен проект- смета документлары хәзерләп куелган. Шулай ук мәдәният йортының залдагы урындыклары тузган, яңа урындык-креслалар алыштырасы бар. Мәдәният йортының ремонт эшләрен башкару соңгы отчет җыелышларында һәрвакыт әйтеп кителә, ләкин әлеге ремонт эшләре буенча, финанс кыенлыкларына терәлеп туктап кала.

Бүгенге җыелышта Әгерҗе муниципаль район башлыгы Макаров Валерий Владимировичның катнашуыннан файдаланып, авыл халкы исеменнән, мәдәният һәм балалар бакчасының тәрәзә рамнарын алыштыру, ремонт үткәрүдә булышлык күрсәтүен сорыйсы килә.

Исәнбай авыл китапханәсе 2013 ел дәвамында айлык һәм еллык планнарга нигезләнеп эш алып барды. Ел барышында китапханәдә системалы рәвештә актуаль темаларга күргәзмәләр ясалды, яңа кайткан китапларга күзәтүләр, балалар белән төрле әдәби чаралар оештырылды.

Авылда халыкка хезмәт күрсәтүче ваклап-сату предприятиесе эшләп тора. авыл халкына ваклап- сату предприятиесенең бер кибете хезмәт күрсәтә. 2013 елда Исәнбай сәүдә предприятиесенең товар әйләнеше 40 млн. сумнан артык, ә Исәнбай сәүдә кибетенең товар әйләнеше 3 млн. 615 мең сумлык тәшкил итә. Уңышлы гына халыкка сәүдә хезмәте күрсәтүдә Симаков Раил, Нурмухаметов

Шәйхенур, Ямалиева Любовь, Терехов Н.В. шәхси кибетләре хезмәт күрсәтә. Кибетләргә товар халык соравы буенча кайтарыла. Кирәкле азык-төлек товарлары, яшелчә, җиләк-җимеш, концелярия, бүләкләр, электр җиһазлары һәрчак күп төрле ассортиментта. Шулай ук кибетләрдә көн-күреш техникасын һәм сезон вакытында төзелеш материаллары товарларын арттырасы бар.

Авылыбызның элемтә -почта бүлекчәсенә йомышы төшмәгән кеше юктыр. Көн буе аннан халык өзелми. Элемтә бүлеге аша ай саен 267 пенсионерга үзвакытында, ай саен өзлексез 2500 мең сумга якын пенсия акчасы тапшырыла. 2013 елда пенсионерларга ел дәвамында 25 млн. 091140 сум пенсия таратылган. Элемтә бүлеге аша 268 кешегә 154 мең сум пособиеләр, субсидияләр бирелә. Утка-газга, телефонга түләү, спутник антенналарына түләү эшләре башкарыла. Шулай ук кәрәзле телефоннарга, ГИБДД штрафлары, балалар бакчасы өчен түләүләр, банклардан алган кредитларны түләү мөмкинлекләре тудырылган. 40 төр журнал, 75 төрле газеталар халыкка яздырылып, үзвакытында авыл халкына таратыла.

Авыл халкына хезмәт күрсәтүче саклык банкы бүлекчәсе атнага бер тапкыр җомга көнне көне буе эшли. Ул 2540 вкладчикка хезмәт күрсәтә һәм 23 пенсионерга пенсия акчасы бирә. Саклык бүлекчәсендә банкларга кредитлар һәм коммуналь хезмәтләргә түләүләр башкарыла.

Исәнбай авыл җирлегендә 11 кешедән торган янгын саклау бүлекчәсе, МЧС хезмәткәрләре ел әйләнәсе Красный бор, тугызбуй зонасындагы авылларны ут-күзләрдә, төрле бәла-казалардан саклау эшләре, республика юлларында төрле авариягә юлыгучыларга булышлык күрсәтү эшләре белән шөгельләнәләр. Авылыбыз, районыбыз өчен иң кирәкле булган МЧС хезмәткәрләре, һәрвакыт уяу булсыннар, имин генә безнең тынычлыгыбызны саклап, ел дәвамында хезмәт итсеннәр.

Хөрмәтле авылдашлар!

Шуның белән отчет доклады тәмам. Әлбәттә, докладта гына авылыбызның тормышындагы һәр нечкәлекне, һәр әйтеләсе, эшләнәсе эшкә тукталып китеп булмый. Шуңа күрә үзегезнең чыгышларыгызда тулыландырырсыз, үз тәкъдимнәрегезне әйтерсез дип ышанып калам. Үзебезнең

авылыбызның киләчәген уйлап, еллар имин булсын, куйган максатларыбызга ирешергә Ходай насыйп итсен.

Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!!!